**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**28.05.2021 ел** **№ 62**

**Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Нурлатского муниципального района Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Советының сәнәгать, транспорт, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин

Нурлат муниципаль районы Советының 2021 елның 28 маендагы 62 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибе**

1 Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибе (алга таба - Тәртип) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында » 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә эшләнде, Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында һәм аларны Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль контроль төрләре исемлеген (алга таба - Исемлек) төзү һәм алып бару процедурасын билгели.

2. Исемлек әлеге Тәртипкә кушымтада билгеләнгән форма буенча Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле органы (алга таба - вәкаләтле орган) тарафыннан төзелә һәм алып барыла.

3. Исемлеккә түбәндәге белешмәләр кертелә:

1) Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төренең исеме;

2) тиешле муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелгән Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты органнарының исеме, аларның урнашкан урыны, телефоны;

3) Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты органының муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен билгели торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы муниципаль норматив хокукый акты, муниципаль норматив хокукый акт исеме һәм реквизитлары;

4) Нурлат муниципаль районының тиешле муниципаль контроль төрен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында муниципаль норматив хокукый акты исеме һәм реквизитлары.

4. Исемлеккә үзгәрешләр кертү Тәртипнең 3 пунктындагы 4 пунктчасында каралган муниципаль норматив хокукый акт кабул ителгән (басылган) көннән алып 10 көн эчендә яисә аңа үзгәрешләр кертелгән көннән алып 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

5. Исемлек Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару тәртибенә кушымта

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашырырга вәкаләтле Башкарма комитет органнары исемлеге**

| Тәртип саны | Муниципаль контроль төре исеме | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органы исеме (урнашу урыны, телефон) | Нурлат муниципаль районының тиешле муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре яисә вазыйфаи затлары исеме (урнашкан урын, телефон) | Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели торган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актның һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актының исеме һәм реквизитлары |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |